КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 апрель

г.Казань

№ 217

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 15 август, 388 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре« 2007 ел, 15 август, 388 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 20 сентябрь, 492 нче; 2007 ел, 29 декабрь, 788 нче; 2008 ел, 17 ноябрь, 818 нче; 2009 ел, 22 июнь, 418 нче; 2010 ел, 1 апрель, 217 нче; 2010 ел, 6 декабрь, 1003 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1041 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 13 декабрь, 1013 нче; 2012 ел, 2 июль, 576 нчы; 2012 ел, 17 сентябрь, 774 нче; 2013 ел, 22 май, 341 нче; 2013 ел, 22 август, 592 нче; 2013 ел, 26 октябрь, 799 нчы; 2013 ел, 19 ноябрь, 896 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 253 нче; 2014 ел, 31 май, 372 нче; 2014 ел, 16 сентябрь, 665 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 12 декабрь, 983 нче; 2015 ел, 11 июнь, 433 нче; 2015 ел, 17 сентябрь, 684 нче; 2015 ел, 14 октябрь, 767 нче; 2015 ел, 22 декабрь, 984 нче; 2016 ел, 31 март, 186 нчы; 2016 ел, 22 июль, 501 нче; 2017 ел, 8 май, 266 нчы; 2017 ел, 13 июнь, 375 нче; 2017 ел, 19 июнь, 390 нчы; 2017 ел, 31 август, 623 нче; 2017 ел, 26 сентябрь, 720 нче; 2018 ел, 15 февраль, 89 нчы; 2018 ел, 11 июнь, 448 нче; 2018 ел, 20 август, 675 нче; 2018 ел, 9 октябрь, 915 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2018 ел, 17 декабрь, 1154 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1322 нче; 2019 ел, 27 февраль, 134 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 769 нчы; 2020 ел, 21 февраль, 127 нче; 2020 ел, 26 март, 219 нчы; 2020 ел, 22 апрель, 317 нче, 2020 ел, 12 июнь, 487 нче, 2020 ел,

29 июль, 634 нче, 2020 ел, 29 август, 757 нче, 2020 ел, 02 октябрь, 903 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән Татарстан Республикасы халкына беренчел медицина-санитария ярдәме, махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәме, ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме һәм паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне оештыру функциясен гамәлгә ашырганда (04.02.04*);

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07*);

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда (04.05.01*) билгеләнгән мәгариф оешмалары типлары һәм белем бирү дәрәҗәләре киселешендә мәгариф идарәсе функциясен гамәлгә ашырганда;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне тормышка ашырганда:

гражданнар оборонасы өлкәсендә идарә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы (02.01*);

гражданнар оборонасы өлкәсендә чаралар оештыру һәм үткәрү белән идарә итү (02.01.01*);

Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү белән идарә итү (02.01.03*);

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

ирекләләр (волонтерлык) эшчәнлеге өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.16*);

дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү (04.07*);

Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасының тышкы икътисадый эшчәнлеге һәм ватандашлар белән мөнәсәбәтләр өлкәсендә эшчәнлек белән идарә итү(01.03*);

энергияне һәм ресурсларны саклау белән идарә итү (01.14*);

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.04*);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

территориаль планлаштыру (01.05.01*);

объектларны төзү, капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү белән идарә итү (01.05.03*);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

дәүләт финанслары белән идарә итү (01.02*);

финанс-бюджет өлкәсендә контроль (01.02.01*);

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

цифрлаштыру белән идарә итү (01.15*);

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү (дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итүдән тыш) (01.15.02*);

Татарстан Республикасының ведомство дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.2 *);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*);

озак вакытлы этапка исәпләнгән социаль-икътисадый программалаштыру (01.01.01*);

планлаштырыла торган елга социаль-икътисадый программалаштыру (01.01.02*);

инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә җайга салу (01.09*);

инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.11*);

социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.1*);

икътисадны мобилизацион әзерләү белән идарә итү (02.04*);

Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә функцияләрен гамәлгә ашырганда (02.03*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17*);

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру функциясен гамәлгә ашырганда (03.05.04*);

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча агентлыгы белән матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә идарә функцияләрен гамәлгә ашырганда (04.10*);

халыкның мәшгульлеге һәм эшсезлек өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы һәм халыкның мәшгульлеге өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, халыкның мәшгульлегенә булышлык итү һәм альтернатив граждан хезмәте өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан халыкның мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү һәм эшсезлектән яклау, хезмәт миграциясе һәм коллектив хезмәт бәхәсләрен җайга салу;

социаль хезмәтләр күрсәтелгәндә һәм социаль ярдәм күрсәтелгәндә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары;

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау чараларын гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары.»;

3.3 пунктта:

3.3.10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.10. Илтеп җиткерүне оештыруны, шулай ук туктатып торуны да кертеп, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар пенсиясенә өстәмә түләүне, Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның пенсияләренә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле еллар эшләгән өчен пенсияләренә, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең тиешле еллар эшләгән өчен пенсияләренә өстәмә түләүләрне билгеләү, яңадан исәпләп чыгару һәм түләүне туктатып тору;

«Татарстан Республикасының аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2006 елның 13 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көченә кергәнче билгеләнгән Татарстан Республикасы алдындагы аерым уңышлары өчен  пенсияләргә өстәмә түләүне туктатып торуны, яңартуны һәм туктатуны кертеп, пенсияләргә өстәмә түләү күләмнәрен һәм түләүне кабатлый.»;

3.3.12 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«озак вакыт тәрбиягә мохтаҗ гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтү чараларын гамәлгә ашыра.»;

3.3.13 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.13. Татарстан Республикасында милли проектлар составында региональ проектлар чараларын гамәлгә ашыра, аларны үтәү өчен җаваплы Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәсе белән Министрлык билгеләнгән.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.38 пунктчасын өстәргә:

«3.3.38. Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген профилактикалау чараларын гамәлгә ашыруда һәм күзәтүчесез һәм сукбайлыкта йөрүче балигъ булмаганнарның, аларның ата-аналарының яисә башка законлы вәкилләренең балигъ булмаганнарны тәрбияләү, карау бурычларын үтәмәүләренә һәм (яисә) аларның үз-үзләрен тотышларына тискәре йогынты ясаучы йә алар белән рәхимсез мөгамәләдә булучыларга карата шәхси профилактика эшен оештыруда катнаша.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин